| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от** 31.01.2022 г. Казань **№** 21/2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.06.2021 № 396/2021 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә чик тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 2209 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.06.2021 №396/2021 боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.10.2021 №587/2021 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә чик тарифлар билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.5.1 пунктының м) пунктчасына үзгәреш кертеп, аны түбәндәгечә бәян итәргә:

«м) җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сату турында шартнамәләрнең, электр энергиясен һәм егәрлеген сату-алу шартнамәләренең күчермәләре яки мондый шартнамәләрнең реестры. Күрсәтелгән реестрда килешү предметы, шартнамә төзү датасы, шартнамәнең гамәлдә булу вакыты, шартнамә буенча гамәлгә ашырыла торган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) күләме турында шартнамә төзегән зат турында белешмәләр (калдыклар белән, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасы нигезендә, каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, зарарсызландыру, күмү һәм энергетика эшчәнлеген мөстәкыйль гамәлгә ашыра торган очрактан тыш) чагылдырылырга тиеш;».

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев